**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Чуаш Тимерлеге ав. **КАРАР**

«09» апрель 2026 ел № 4

2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (29.12.2025 нче редакциядә), «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 28 п., «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы чараларының үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.
3. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы чараларын тиешле финанс елына Тимерлек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетында шушы максатларга каралган ассигнованиеләр чикләрендә финансларга.
4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru / һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Җитәкче В.И.Гаврилов